ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасында архив эше турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар, шулай ук алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм, милек рәвешенә бәйсез рәвештә, башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне, шулай ук Татарстан Республикасында архив эше белән идарә итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Татарстан Республикасында архив эше өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

1. Татарстан Республикасында архив эше өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.
2. Җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре кысаларында архив эше өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган муниципаль хокукый актлар кабул итәргә хокуклы.

3 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:
1) Татарстан Республикасында архив эше (алга таба – архив эше) – дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм гражданнарның

Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыру өлкәсендәге эшчәнлеге;

2) Татарстан Республикасының Архив фонды – җәмгыятьнең матди һәм рухи тормышын чагылдыручы, тарихи, фәнни, социаль, икътисадый, сәяси һәм мәдәни әһәмияткә ия булган, Татарстан Республикасы халыклары тарихи-мәдәни мирасының аерылгысыз өлеше булып торучы, мәгълүмат ресурсларына карый торган, даими сакланылырга тиешле һәм Россия Федерациясе Архив фондының состав өлеше булып торучы архив документларының тарихи барлыкка килгән һәм даими тулыландырыла торган тупланмасы;

3) Татарстан Республикасы Архив фондының Республика уникаль документлар реестры – уникаль документларның әлеге документларны табу, исәпкә алу һәм аларның сакланышын тәэмин итү максатларында төзелә торган системалаштырылган исемлеге.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Федераль законда билгеләнгән мәгънәдә кулланылалар.

4 статья. **Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) архив эшен оештыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) архив эше өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм гамәлгә ашыруны тикшереп тору;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

5 статья. **Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә архив эше өлкәсендә дәүләт сәясәте уздыру;

2) архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итү;

3) архив эше өлкәсендә дәүләт программаларын раслау;

4) Татарстан Республикасы дәүләт архивларын булдыру һәм тәэминатта тоту;

5) Татарстан Республикасы милкендә булган архив документларын Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм (яки) муниципаль берәмлекләр милкенә күчерү турындагы мәсьәләләрне хәл итү.

6 статья. **Архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләре**

Архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә архив эше өлкәсендә идарә итү һәм җайга салу;

2) түбәндәгеләрнең архив документларын һәм архив фондларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм алардан файдалану:

а) Татарстан Республикасы дәүләт архивларының, музейларының, китапханәләренең;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм башка дәүләт органнарының;

в) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең, казна предприятиеләрен дә кертеп, һәм дәүләт учреждениеләренең (алга таба – дәүләт оешмалары);

3) архив эше өлкәсендә дәүләт программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

4) үз вәкаләтләре чикләрендә архив эше турында законнар үтәлешен тикшереп тору;

5) үз вәкаләтләре чикләрендә архив эше өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлектә катнашу;

6) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

7 статья. **Архив эше өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Архив эше өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) түбәндәгеләрнең архив документларын һәм архив фондларын саклау, туплау (формалаштыру), исәпкә алу һәм алардан файдалану:

җирле үзидарә органнарының, муниципаль архивларның, музейларның, китапханәләрнең;

муниципаль унитар предприятиеләрнең, казна предприятиеләрен дә кертеп, һәм муниципаль учреждениеләрнең (алга таба – муниципаль оешмалар);

2) муниципаль милектә булган архив документларын Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм (яисә) муниципаль берәмлекләр милкенә күчерү турындагы мәсьәләләрне хәл итү.

8 статья. **Татарстан Республикасы Архив фонды составы**

Татарстан Республикасы Архив фонды составына, килеп чыгу чыганакларына, барлыкка килү вакытына һәм ысулына, нинди төрдә саклануына, милек рәвешенә һәм саклану урынына бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендәге архив документлары, шул исәптән юридик актлар, идарә документлары, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык эшләре һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен үз

эченә алган документлар, шәһәр төзелеше документлары, кино-, фото-, видео- һәм фонодокументлар, электрон һәм телеметрик документлар, кулъязмалар, рәсемнәр, сызымнар, көндәлекләр, хатлар, мемуарлар, архив документларының төп нөсхә хокукындагы күчермәләре, шулай ук әлеге Законның 6 статьясындагы 2 пунктында һәм 7 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән, Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан оешмаларның архив документлары керә.

9 статья. **Архив документларын Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертү**

1. Федераль закон нигезендә архив документлары Татарстан Республикасы Архив фонды составына архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының эксперт-тикшерү комиссиясе тарафыннан документларның кыйммәтен билгеләү буенча ясалган экспертизага таянып кертелә.

2. Архив документларын Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертү турында карар шулай ук дәүләт музейларының һәм муниципаль музейларның эксперт фонд сатып алу комиссияләре, дәүләт китапханәләренең һәм муниципаль китапханәләрнең эксперт комиссияләре, Федераль закон нигезендә билгеләнгән фәнни оешмаларның эксперт-тикшерү комиссияләре (алга таба – эксперт комиссияләре) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Документларның кыйммәтен билгеләүгә экспертиза архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, дәүләт архивы, муниципаль архив тарафыннан архив документларының милекчесе яисә хуҗасы белән берлектә гамәлгә ашырыла.

4. Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган теләсә кайсы төр саклагычлардагы барлык документларга да кыйммәтен билгеләүгә экспертиза ясалырга тиеш. Документларның кыйммәтен билгеләүгә тиешле тәртиптә экспертиза ясалганга кадәр документларны юк итү тыела.

10 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган архив документлары**

Татарстан Республикасы дәүләт милкенә түбәндәге архив документлары карый:

1) Татарстан Республикасы дәүләт архивларында, музейларында һәм китапханәләрендә саклана торган (әлеге архивларга, музейларга һәм китапханәләргә милеккә рәсмиләштермичә, саклау шартнамәсе нигезендә тапшырылган архив документларыннан тыш) архив документлары;

2) Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм дәүләт оешмаларының архив документлары;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы милкенә күчкән архив документлары.

11 статья. **Муниципаль милеккә караган архив документлары**

Муниципаль милеккә түбәндәге архив документлары карый:

1) җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль оешмаларның архив документлары;

2) муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә саклانучы (әлеге архивларга, музейларга һәм китапханәләргә милеккә рәсмиләштермичә, саклау шартнамәсе нигезендә тапшырылган архив документларыннан тыш) архив документлары.

12 статья. **Хосусый милеккә караган архив документлары**

Хосусый милеккә түбәндәге архив документлары карый:

1) Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче һәм дәүләтнеке яисә муниципаль булмаган оешмаларның, шул исәптән, иҗтимагый берләшмәләр турында Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән көненнән алып, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм чиркәү дәүләттән аерылганнан соң дини берләшмәләрнең архив документлары;

2) гражданнар тарафыннан булдырылган яки алар тарафыннан законлы юл белән алынган архив документлары.

13 статья. **Татарстан Республикасы милкендәге архив документларының хокукый хәле үзенчәлекләре**

Татарстан Республикасы милкендәге архив документларын Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм (яки) муниципаль берәмлекләр милкенә тапшыру архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

14 статья. **Архивлар булдыру**

Дәүләт органнары, муниципаль районның җирле үзидарә органнары, шәһәр округы җирле үзидарә органнары үз эшчәнлекләре барышында барлыкка килгән архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм алардан файдалану өчен архивлар булдырырга тиеш.

15 статья. **Татарстан Республикасында архив эшенә дәүләт идарәсе**

1. Татарстан Республикасында архив эшенә дәүләт идарәсе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, шул исәптән архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы үз эшчәнлеген Татарстан Республикасының башка дәүләт

органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән үзара эшчәнлектә турыдан-туры һәм ведомство буйсынуындагы архив учреждениеләре һәм оешмалар аша гамәлгә ашыра.

16 статья. **Архив эшен финанс ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү**

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм юридик зат булдырмый гына эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм алардан файдалану өчен кирәкле финанс, матди-техник һәм башка шартларны тәэмин итәргә, үзләре тарафыннан булдырылган архивларга архив документларын саклауның һәм архив хезмәткәрләре эш шартларының норматив таләпләренә җавап бирә торган биналар һәм (яки) бүлмәләр бирергә тиешләр.

2. Дәүләт архивы яки муниципаль архив урнашкан бинаны төзекләндерү, тапшыру яки сүтү турында карар кабул итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы әлеге архивка архив документларын саклауның норматив таләпләренә җавап бирә торган бина бирергә тиеш.

17 статья. **Архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору**

Архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору дәүләт органнары, шул исәптән архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан башкарыла.

18 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм юридик зат булдырмый гына эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнарның архив документларының сакланышын тәэмин итү бурычлары**

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм юридик зат булдырмый гына эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар архив документларының, шул исәптән шәхси состав буенча документларның федераль законнарда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән сроклар дәвамында сакланышын тәэмин итәргә тиешләр.

2. Аеруча кыйммәтле документларга, шул исәптән уникаль документларга карата саклауның, исәпкә алуның һәм алардан файдалануның Федераль закон нигезендә аерым режимы билгеләнә.

19 статья. **Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклау һәм дәүләт исәбенә алу**

1. Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклау, шулай ук әлеге документларны дәүләт архивларына һәм муниципаль архивларга даими саклауга тапшыру өчен сайлап алу, әзерләү һәм тапшыру Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Архив фонды документлары, саклану урыннарына бәйсез рәвештә, Федераль закон нигезендә дәүләт исәбенә алынырга тиеш. Уникаль документлар шулай ук Татарстан Республикасы Архив фондының Республика уникаль документлар реестрында да исәпкә алынырга тиеш, әлеге реестр архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан үзе билгели торган тәртиптә алып барыла.

3. Татарстан Республикасы Архив фонды документлары аларның сакланышын гамәлгә ашыручы оешмалар милке составына керми.

20 статья. **Дәүләт архивларына һәм муниципаль архивларга архив документларын туплау чыганаклары**

1. Эшчәнлекләре барышында Татарстан Республикасы Архив фонды документлары һәм саклау өчен дәүләт архивлары, муниципаль архивлар кабул итәргә тиешле башка архив документлары барлыкка килә торган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар дәүләт архивларына һәм муниципаль архивларга архив документларын туплау чыганаклары булып тора.

2. Дәүләт архивлары һәм муниципаль архивлар әлеге архивларга Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм башка архив документларын тапшыручы туплау чыганакларының исемлекләрен төзиләр. Дәүләтнеке булмаган оешмаларны, шулай ук гражданнарны әлеге исемлекләргә кертү шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

21 статья. **Архив документларыннан файдалана алу**

1. Архив документларыннан файдаланучы архив документларын ирекле эзләргә һәм өйрәнү өчен алып торырга хокуклы.

2. Архив документларыннан файдалана алу түбәндәге юллар белән тәэмин ителә:

1) белешмә – эзләү чараларын һәм алар турында мәгълүмат бирү, шул исәптән электрон документ рәвешендә;

2) кирәкле документларның төп нөсхәләрен һәм (яисә) күчермәләрен бирү, шул исәптән электрон документ рәвешендә;

3) архив документларының күчермәләрен алу мөмкинлеге булган гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән Интернет челтәреннән файдалану.

3. Архив документларыннан файдалана алуга Федераль законда билгеләнгән очракларда чикләүләр билгеләнергә мөмкин.

22 статья. **Архив документларыннан файдалану**

1. Дәүләт архивлары һәм муниципаль архивлар, музейлар, китапханәләр, шулай ук фәнни оешмалар архив документларыннан файдаланучыга архив документларын эзләү һәм өйрәнү өчен кирәкле шартларны тәэмин итәләр.

2. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм юридик зат булдырмый гына эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар, үзләрендә тиешле архив документлары булган очракта, гражданнарны социаль яклауга бәйле, аларның пенсия белән тәэмин ителешен, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә ташламалар һәм компенсацияләр алуны күздә тоткан, тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән архив белешмәләрен яисә архив документларының күчермәләрен архив документларыннан файдаланучыга түләүсез нигездә бирергә тиешләр. Архив документларыннан файдаланучыларның гарызнамәләре һәм мөрәҗәгатьләре гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән Интернет челтәреннән файдаланып, электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

3. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт архивлары һәм муниципаль архивлар (җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләреннән тыш), музейлар, китапханәләр, эксперт комиссияләре, шулай ук дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар архив документларыннан файдаланучыга үзләрендә булган архив документлары һәм белешмә – эзләү чаралары нигезендә түләүле мәгълүмати хезмәтләр күрсәтергә, архив документларыннан һәм белешмә – эзләү чараларыннан файдалану турында аның белән шартнамәләр төзергә мөмкин.

4. Дәүләт архивлары һәм муниципаль архивлар, музейлар, китапханәләр, эксперт комиссияләре, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар архивлары дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына үзләренең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле архив мәгълүматын һәм архив документларының күчермәләрен бирәләр, шул исәптән электрон документлар формасында да, архив документларын бастырып чыгаралар һәм алардан экспозицияләр эшлиләр, үзләрендә саклана торган документларның составы һәм эчтәлеге турында белешмә-мәгълүмат басмалары әзерлиләр.

23 статья. **Архив эше өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек**

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт архивлары һәм муниципаль архивлар, музейлар, китапханәләр һәм башка юридик затлар үз вәкаләтләре чикләрендә, шулай ук гражданнар – архив документлары милекчеләре яисә хуҗалары архив эше өлкәсендә халыкара хезмәттәшлектә, архив эше мәсьәләләре буенча халыкара оешмалар эшендә, киңәшмәләрдә һәм конференцияләрдә, халыкара мәгълүмат алмашуда катнашалар.

24 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасының Архив фонды һәм архивлар турында» 1996 елның 13 июнендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 7);

2) «Татарстан Республикасының Архив фонды һәм архивлар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 елның

28 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш).

25 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2017 ел, 20 июль
№ 63-ТРЗ